**Территориальная избирательная комиссия**
**Балтасинского района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Балтач районы**
**территориаль сайлау комиссиясе**

ул. Ленина,42, пгт.Балтаси, 422250 Ленин ур.,42, штб.Балтач, 422250
тел.: (84368) 2-56-85

---

# Карар

11 июнь 2019 ел № 292

## Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советына депутатларны 1 нче һәм 2 нче бермандатлы сайлау округлары буенча өстәмә сайлаулар билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 10 статьясындагы 7 пункты, 71 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьяның 1 өлеше, 123 статьясындагы 1, 2 өлешләре нигезендә, “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы», «Борбаш авыл җирлеге», «Борнак авыл җирлеге», «Югары Субаш авыл җирлеге», «Карадуган авыл җирлеге», «Куныр авыл җирлеге», «Кече Лызи авыл җирлеге», «Норма авыл җирлеге», «Нөнәгәр авыл җирлеге», «Пыжмара авыл җирлеге», «Салавыч авыл җирлеге», «Смәил авыл җирлеге», «Сасна авыл җирлеге», «Чепья авыл җирлеге», «Шубан авыл җирлеге», «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең сайлау комиссияләре вәкаләтләрен йөкләү турында” Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2015 елның 14 апрелендәге 57/592 номерлы карарын исәпкә алып, “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге” берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы депутаты Кәлимуллин Фәнил Фәрит улының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында” Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 сентябрендәге 104 номерлы карары, “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы депутаты Рамазанов Алмаз Илдар улының вакытыннан алда вәкаләтләрен туктату турында” 2019 елның 20 маендагы 136 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач районы территориаль сайлау комиссиясе **карар итте:**

1. Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советына депутатларны 1 нче һәм 2 нче бермандатлы сайлау округлары буенча өстәмә сайлауларны 2019 елның 8 сентябренә билгеләргә.

2.Әлеге карарны “Хезмәт” район газетасында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балтач районы территориаль сайлау комиссиясе сайтында урнаштырырга.

Балтач районы территориаль
сайлау комиссия рәисе ____________ Р.В.Каримов
*имза* *инициаллар, фамилия*

**М.П.**

Балтач районы территориаль
сайлау комиссия секретаре ____________ Р.Х.Мухаметзянова
*имза* *инициаллар, фамилия*